КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 июнь г.Казань № 395

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карары белән расланган 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында» 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карары белән расланган 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү методикасына, аны яңа редакциядә (升карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 ноябрь, 1532 нче карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 3 июнь, 395 нче карары редакциясендә)

2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү
методикасы

1. Татарстан Республикасының i муниципаль районы өчен башка бюджетара трансфертлар күләме ($S_i$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = \sum_{j=1}^{n} S_j,$$

монда:

n – заявкага кертелгән, 2023 елның II – IV кварталларында һәм 2024 елның I кварталында бюджетларына 2023 елда җирле референдумнарда (гражданнар җыеннарында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карарлар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча кергән, Татарстан Республикасы i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасы авыл һәм шәһәр җирлекләре саны;

$S_j$ – Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме. Аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_j = R_j + ОФ_{өстj},$$

монда:

$R_j$ – Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның исәпләнгән күләме;

$ОФ_{өстj}$– Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның өстәмә күләме, әгәр $К_с \times ФСс_j > МТп_j$ булса, монда:

$К_с$ – гражданнарның үзсалым акчасын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына кергән гражданнарның үзсалым акчасының 1 сумына бирелә торган, түбәндәге сумнарга тигез итеп алынган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме:

4 сумга – Татарстан Республикасының авыл, шәһәр җирлекләре өчен (Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегеннән тыш);

3 сумга – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге өчен;

$ФСс_j$ – 2023 елның II – IV кварталларында һәм 2024 елның I кварталында Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлекләре бюджетларына 2023 елда җирле референдумда (гражданнар җыенында) гражданнарга үзара салым кертү турында кабул ителгән карарлар нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акча кергән гражданнарның үзара салым акчасы күләме, сум;

$МТп_j$ – Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлекләре өчен гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның норматив күләме.

2. – Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның исәпләнгән күләме ($R_j$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$R_j = К_с \times ФСс_j,$$
$$\text{әгәр } R_j > МТп_j, \text{ то } R_j = МТп_j.$$

3. Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлекләре өчен гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның норматив күләме ($МТп_j$):

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлары булмаган Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре өчен түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$МТп_j = Ч_j \times МТг \times К_с,$$

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган торак пунктлар составындагы Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлекләре өчен түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$МТп_j = (Ч_t^i - Ч_t^{ik}) \times МТг \times К_с,$$

монда:

$Ч_j$ – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булган, составында торак пункт булмаган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлегенең даими халкы саны, кеше;

$Ч_t^i$ – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы i муниципаль районының административ үзәге булган, составында торак пункт булган t авыл, шәһәр җирлегенең даими халкы саны, кеше;

$Ч_t^{ik}$ – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматлары буенча 2023 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының t авыл, шәһәр җирлеге составына керә торган, Татарстан Республикасы i муниципаль районындагы k торак пунктының – административ үзәгенең даими халкы саны, кеше;

МТг – гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасының норматив күләме Татарстан Республикасы авыл, шәһәр җирлегенең бер кешесенә түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$МТг = \frac{ОСсп}{\sum_{j=1}^{m} Ч_j \times К_c + \sum_{t=1}^{n} (Ч_t^i - Ч_t^{ik}) \times К_c},$$

монда:

ОСсп – 2024 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме, сум;

m – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган, составында торак пунктлары булмаган Татарстан Республикасының авыл һәм шәһәр җирлекләре саны;

n – Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган, составында торак пунктлар булган Татарстан Республикасының авыл һәм шәһәр җирлекләре саны.

4. Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның исәпләнгән күләме($ОФ_{өстj}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$ОФ_{өстj} = ОФ_{яңадан\ бүлүj} \times К_i,$$

монда:

$ОФ_{яңадан\ бүлү}$ – Татарстан Республикасының j авыл, шәһәр җирлеге өчен яңадан бүленә торган акчаның түбәндәге формула буенча исәпләнә торган күләме:

$$ОФ_{яңадан\ бүлүj} = К_с \times ФСс_j – МТп_j;$$

$К_i$ – Татарстан Республикасының i муниципаль районы җирлекләре өчен акчаны яңадан бүлү коэффициенты:

а) Татарстан Республикасының i муниципаль районы өчен, монда $\sum_{j=1}^{h} ОФ_{калдыкj} < \sum_{j=1}^{m} ОФ_{яңадан\ бүлүj}$, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К_i = \frac{\sum_{j=1}^{h} ОФ_{калдыкj}}{\sum_{j=1}^{m} ОФ_{яңадан\ бүлүj}},$$

монда:

h – Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасы шәһәр, авыл җирлекләре саны, $МТп_j > К_с \times ФСс_j$;

$ОФ_{калдыкj}$ – гражданнарның үзара салым акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасының j шәһәр, авыл җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның норматив күләменнән калган өлеше, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$ОФ_{калдыкj} = МТп_j - К_с \times ФСс_j;$$

m – Татарстан Республикасының i муниципаль районы составына керә торган Татарстан Республикасы шәһәр, авыл җирлекләре саны, $К_с \times ФСс_j > МТп_j$;

б) Татарстан Республикасының i муниципаль районы өчен, монда $\sum_{j=1}^{h} ОФ_{калдыкj} > \sum_{j=1}^{m} ОФ_{яңадан\ бүлүj}$, 1гә тигез итеп алына.

---